ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа утыз җиденче абзац өстәргә:
"региональ дәүләт экология күзәтчелегендә булырга тиешле объектларда индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш) калдыклар барлыкка китерә торган хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлегенә карата калдыклар барлыкка китерү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектларын әзерләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау;";
б) утыз җиденче абзацны утыз сигезенче абзац дип санарга;

2) 34 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:
1) "Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 16 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 5 (I өлеш); 2015, № 4);
2) "Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2013 елның 12 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

1 статьясындагы 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1; 2014, № 5; 2015, № 4);

3) “Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 7 мае
№ 30-ТРЗ